# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның беренче өлешендә "хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясендә билгеләнгән 3000 минималь күләменнән" сүзләрен "400 мең сумнан" сүзләренә алмаштырырга;

2) $10^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 11 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) яшь гаилә тарафыннан бирелгән документларда дөрес булмаган яисә бозып күрсәтелгән белешмәләрнең булуы;

2) әлеге Законның 4 статьясында каралган нигезләрнең булмавы.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 12 декабре
№ 97-ТРЗ